РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава Балыклы-Чукаевского сельского поселения Рыбно-Слободского муниципального района
индекс 422655 , с.Балыклы-Чукаево ул.Центральная, дом 8

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге башлыгы
индекс 422655, Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк ур., 8 йорт

Тел.: (84361) 26357, факс: (84361) 26357, эл.адрес: Blc.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Балыклы-Чүкәй ав. № 2 11 ноябрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең Иске Арыш авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең Иске Арыш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2025 елның 20 ноябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла дип билгеләргә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең Балыклы-Чүкәй авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, өлешчә мобилизацияләүгә бәйле рәвештә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле

автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү
- Су системаларын карау хэм ремонтлап тору.
- Торак пункт чиклэрендэ урам утлары системасын карау хэм ремонтлау.
“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

5. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урамы,8 йорт; Иске Арыш авылы, Үзәк урамы, 23А йорт; Керәшен Казысы авылы, Титов урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб- адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

6. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Башлыгы: И.С.Мазитов